**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2017 Балык Бистәсе штп. № 226пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында»2014 елның 9 сентябрендәге 161п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы , «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 20 июлендәге 60-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» гы 2014 елның 9 сентябрендәге 161пп номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 15 июлендәге 195пи, 17.08.2016елның 17 августындагы 133пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1.Үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.1 (дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма турында үз исеме һәм мәгълүмат элмәтәсендә урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы

законнарын бозуга карата), 2.6, 2.8, 2.14, 3.2, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.16, 5.1, 5.2, 5.6 (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуга карата) статьяларда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә.»;

1.2) карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2.Әлеге карар 2017 елның 20 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 9
сентябрендәге 161пи номерлы
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның
18октябрендәге 226пи номерлы
карары редакциясендә)

**Үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.1 (дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма турында үз исеме һәм мәгълүмат элмәтәсендә урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.6, 2.8, 2.14, 3.2, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.16, 5.1, 5.2, 5.6 (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуга карата) статьяларда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

I. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.1 (дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма турында үз исеме һәм мәгълүмат элмәтәсендә урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата) статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары (укыту-методик эш буенча);
- «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең милли мәгариф буенча методисты.

Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.6, 2.8, 2.14, 3.2, 3, 3.16, 5.1, 5.2, 5.6 (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуга карата) статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы урынбасары.

III. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.6, 3.3-3.7, 3.10 (гражданнарга карата), 3.16 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары.

IV. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау пунктлары эшчәнлеген тәэмин итү секторының әйдәп баручы белгече (балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор)